**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 февраля 2014 года № УП-217 «О Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2014 года № УП-1065, от 30 июля 2015 года № УП-688, от 20 марта 2017 года № УП-231, от 3 июня 2017 года № УП-459, от 14 октября 2017 года № УП-911, от 2 февраля 2019 года № УП-58, от 5 июня 2020 года № УП-339, от 18 февраля 2021 года № УП-154, от 2 марта 2021 года № УП-194, указами Раиса Республики Татарстан от 25 июля 2023 года № 506 и от 26 июля 2024 года № 565) следующие изменения:

а) в абзаце четвертом пункта 3 Положения о Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан слова «на обеспечение своевременной выплаты работодателями заработной платы в размере не ниже стоимостной величины минимального потребительского бюджета и уплаты страховых взносов в государственные внебюджетные фонды,» исключить;

б) в составе Республиканской межведомственной комиссии по вопросам повышения уровня жизни населения, труда, привлечения и использования иностранных работников в Республике Татарстан (далее – Комиссия):

вывести из состава Комиссии А.Л. Анфимову, Э.Я. Вафина, А.Х. Зайнутдинову, А.Н. Кудрявцеву, И.Р. Метшина, А.С. Николаева, П.М. Олейника, В.Г. Перепелкина, М.В. Прокофьеву, И.Р. Фатихова, А.М. Фролова, Л.Н. Шафигуллина;

ввести в состав Комиссии:

Авдонину Любовь Геннадьевну – заместителя руководителя Управления Федеральной службы по надзору в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по Республике Татарстан (Татарстан) (по согласованию);

Гафарова Рустема Гильфановича – руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию);

Гревцова Андрея Борисовича – заместителя директора государственного бюджетного учреждения «Центр экономических и социальных исследований Республики Татарстан при Кабинете Министров Республики Татарстан»;

Дулкарнаева Марселя Саримовича – заместителя руководителя следственного управления Следственного комитета Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

Карпухина Сергея Владимировича – заместителя председателя по экономическим вопросам Союза «Торгово-промышленная палата Республики Татарстан» (по согласованию);

Кисапову Оксану Алексеевну – заместителя министра финансов Республики Татарстан;

Семенову Веру Сергеевну – заместителя министра здравоохранения Республики Татарстан;

Хисматуллина Ильсура Хайдаровича – начальника управления персонифицированного учета и администрирования страховых взносов Отделения Фонда пенсионного и социального страхования Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

Хохорина Антона Олеговича – руководителя структурного подразделения Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан (по согласованию);

Хусаинова Рягата Галиагзамовича – председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по экономике, инвестициям и предпринимательству (по согласованию);

Шайдуллина Дамира Фаритовича – первого заместителя министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан;

Шашурова Сергея Евгеньевича – руководителя Государственной инспекции труда в Республике Татарстан – главного государственного инспектора труда в Республике Татарстан (по согласованию);

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комиссии:

Р.Н. Валиуллина – «депутат Государственного Совета Республики Татарстан, заместитель председателя региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» – руководитель Исполнительного комитета Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию)»;

Л.К. Сафиуллиной – «первый заместитель министра транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
17 июля 2025 года
№ 547

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге ПУ-339 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы ПУ-194 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 июлендәге 506 номерлы һәм 2024 елның 26 июлендәге 565 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәнең 3 пункты дүртенче абзацында «эш бирүчеләр тарафыннан минималь куллану бюджетының кыйммәте зурлыгыннан түбән булмаган күләмдәге эш хакын үз вакытында түләүне һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен түләүне тәэмин итүгә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан А.Л. Анфимованы, Э.Я. Вафинны, А.Х. Зәйнетдинованы, А.Н. Кудрявцеваны, И.Р. Метшинны, А.С. Николаевны, П.М. Олейникны, В.Г. Перепелкинны, М.В. Прокофьеваны, И.Р. Фатыйховны, А.М. Фроловны, Л.Н. Шәфигуллинны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Авдонина Любовь Геннадьевнаны – Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Гревцов Андрей Борисовичны – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасарын;

Дөлкарнәев Марсель Сарыйм улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Карпухин Сергей Владимировичны – «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасарын (килешү буенча);

Кисапова Оксана Алексеевнаны – Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын;

Семенова Вера Сергеевнаны – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарын;

Хисмәтуллин Илсур Хәйдәр улын – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге иминият кертемнәрен шәхси исәпкә алу һәм аларга күзәтчелек итү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Хохорин Антон Олеговичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе структур бүлекчәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Хөсәенов Рәгать Галиәгъзам улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисен (килешү буенча);

Шәйдуллин Дамир Фәрит улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын;

Шашуров Сергей Евгеньевичны – Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторын (килешү буенча);

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Вәлиуллинның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

Л.К. Сафиуллинаның – «Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 17 июль
№ 547